ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 февраль 2020ел № 545

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 номерлы, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 номерлы, 2017 елның 8 февралендәге 588 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2747 номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4000 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 4226 номерлы, 2018 елның 2 августындагы 4343 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 5755 номерлы, 2019 елның 3 декабрендәге 6264 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлектәге 87 пунктны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«87. Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЁННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ